КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# Тузан суыргыч кая киткән?

Әгәр сатучы таләпләрне үтәү вакытын бозса.

**Түбән Камада яшәүче Р., яңа тузан суыргыч сатып алгач, берникадәр вакыттан соң аның эшләгәндә бик нык кызуына игътибар иткән. Җиһаз гарантиядә булганлыктан, ул аны җитешсезлеген бетерү өчен кибеткә биргән һәм сатучыга тиешле таләпләр күрсәтелгән дәгъва тапшырган. Товарны ремонтка алу турында акт төзелгән. Ай ярым узганнан соң кулланучыга, куелган таләпләрне канәгатьләндерү өчен товарны кибеткә тапшырырга кирәклеген әйтеп, җавап хаты килгән. Тузан суыргыч кая киткән соң?**

Сатучыдан аңлаешлы җавап булмагач, кулланучы озак вакытлар товарны да, аның өчен түләнгән акчаны да ала алмаган. Нәтиҗәдә, ул Түбән Кама территориаль органының эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлегенә үз хокукларын яклауны сорап мөрәҗәгать иткән һәм анда үзенең язма хатын калдырган. Белгечләр тарафыннан юридик зат адресына законнарны аңлатып мөрәҗәгать әзерләнгән. 1992 елның 7 февралендә кабул ителгән «Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ Законының 20 маддәсе нигезендә, әгәр товардагы җитешсезлекне бетерү вакыты якларның килешүе белән язма рәвештә билгеләнмәсә, әлеге кимчелекләр кичекмәстән, ягъни гадәттә кулланыла торган алымны исәпкә алып аларны төзәтү өчен кирәкле минималь вакыт эчендә бетерелергә тиеш.



Якларның килешүе белән язма рәвештә билгеләнә торган товарның кимчелекләрен бетерү вакыты кырык биш көннән дә артып китә алмый.

Нәтиҗәдә, вәзгыять кулланучы файдасына хәл ителгән: аңа тузан суыргыч акчасын кайтарып биргәннәр.

**Үз хокукларыгызны яклаудан курыкмагыз! Күп кенә сатучылар һәм башкаручылар, бөтен нечкәлекләрне белеп төзелгән дәгъваларны күргәч, эшне судка кадәр җиткермәскә тырыша һәм кулланучыларның таләпләрен канәгатьләндерә, чөнки эшнең судта каралуыннан һәм суд чыгымнарыннан (алар товар бәясеннән сизелерлек артып китә) куркалар.**

# Хезмәт күрсәтүдән баш тартсаң – штраф!

**«Минем ахирәтем – инвалид. Без еш аралашабыз. Һәм телефон аша гына түгел: өенә дә барам, кайчагында урамда йөрибез һәм кафега берәр чынаяк каһвә эчәргә керәбез. Әмма күптән түгел, яныбызга килеп, башка кафега баруыбызны сорадылар һәм моны даими клиентларның канәгать булмавы белән аңлаттылар. Законда җәмәгать урыннарыннан файдаланганда сәламәтлегендә кимчелекләр булган кешеләрнең хокукларын яклау каралганмы?**

**Ольга П.»**

Дөрестән дә, инвалидлар, өлкән яшьтәгеләр һәм социаль яктан якланмаган башка категориягә керүче гражданнарны транспорт инфраструктурасы, куллану, ял өлкәсе объектлары һәм хезмәтләреннән файдалану мөмкинлегеннән мәхрүм итү очраклары ешайды. Еш кына моның сәбәпчесе формаль, менталь, маркетинг, имидж һәм башка характерда була.

Шуны күздә тотып, РФ Президенты күрсәтмәсе белән, «РФ Административ хокук бозулар кодексының 14.8 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында»гы закон проекты әзерләнде. Анда әлеге маддәне, закон нигезендә билгеләнгән очраклардан тыш, хокук бозуның яңа составы (кулланучыга аның эшчәнлеген чикләү, сәламәтлек торышы яки яше белән бәйле сәбәпләр буенча товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу, файдалану мөмкинлегеннән мәхрүм итү) белән тулыландырырга тәкъдим ителә.

**Роспотребнадзорга (аның территориаль органнарына) социаль яктан якланмаган категориягә керүче кулланучылардан мөрәҗәгатьләр килгән очракта, мондый гражданнарның хокукларын яклау һәм торгызу өчен тиешле барлык чаралар да күреләчәк.**

**Социаль яктан якланмаган категориягә керүче гражданнарга карата дискриминация күренешләре өчен закон нигезендә штраф санкцияләре кертү күздә тотыла. Вазифаи затлар өчен аның күләме – 15-30 мең, юридик затлар өчен 50-100 мең сум тәшкил итә.**

